**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «14 » мая 2019 г. № 751

Питрәч муниципаль районы территориясендә янгынга каршы
махсус режим билгеләү турында

Язгы-җәйге чорда янгын куркынычы дәрәҗәсе арту сәбәпле, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2019 елның 15 апреленнән башлап 01 июненә кадәр Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләргә.

2.Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда тыюны:
коры үлән һәм чүп яндыру;
ачык утка азык әзерләү (учак, мангалы), урман янгыннары куркынычы янаган торак пунктлар территорияләрендә, гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерцияле булмаган берләшмәләре, балалар сәламәтләндерү лагерьлары, икътисад объектлары, урман кишәрлекләре белән чиктәш сәламәтләндерү оешмалары территорияләрендә, шулай ук урман-парк зоналарында, торфалы участокларда һәм ачык территорияләрдә куркынычлылык 1-3 сыйныф пиротехника әйберләрен куллану.

3. Питрәч муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

торак пунктларны һәм икътисад объектларын ландшафт янгыннарыннан саклау өчен минеральләштерелгән полосалар булдыру, территорияне чүп-чардан һәм коры-сарыдан чистарту эшен оештырырга;

янгыннарны сүндерү өчен су сибү һәм янгын сүндерү өчен җайлаштырылган башка техниканы җәлеп итүне оештырырга;

торак пунктларны һәм объектларны янгынга каршы су белән тәэмин итү буенча өстәмә чаралар күрергә;

торак пунктлар территориясендә янгын чыккан очракта кешеләргә хәбәр итү өчен тавыш сигнализациясе чаралары урнаштыруны тәэмин итәргә;

сулыкларны, ясалма сулыкларга керү юлларын урнаштыру, шулай ук су башняларын янгын техникасы белән су алу өчен җайланмалар белән тәэмин итү һәм янгынга каршы су чыганаклары ремонтлауны оештырырга;

корыган үләнне, агач-куак калдыкларын яндыруга юл куймау буенча чаралар кабул итүне оештырырга.

4. Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе:

комиссия утырышларында торак пунктларда һәм муниципаль районның авыл хуҗалыгы предприятиеләре объектларында янгын куркынычсызлыгы торышы мәсьәләләрен карарга;

территориаль подсистеманың муниципаль звеноларның табигый янгыннарны сүндерүгә көчләре һәм чаралары әзерлеген тикшерүне үткәрергә;

табигать янгыннары барлыкка килгән очракта халыкны хәбәр итү һәм эвакуацияләү мәсьәләләрен эшләргә.

5. ПСЧ-126 ФГКУ «ТР буенча 7 ОФПС» (Волков В. А.), Питрәч районы буенча ОДН һәм ПР (Лобода М. В.) тәкъдим итәргә.:

урман янгыннары куркынычы янаган торак пунктларның паспортларын эшләүдә (актуальләштерү) җирле үзидарә органнарына консультатив һәм методик ярдәм күрсәтергә;

торак пунктларны, икътисад объектларын табигый янгыннардан саклауны контрольгә алырга, шулай ук табигый янгын чыганакларын үз вакытында ачыклау һәм табылган көнне юкка чыгару буенча эш оештырырга;

гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре территорияләренең янгынга каршы торышын тикшерү;

балалар сәламәтләндерү лагерьларына, транспорт, энергетика һәм социаль инфраструктура объектларына, урман янгыннары куркынычы янаган урман эшкәртү предприятиеләренә, шулай ук торак пунктлар белән чиктәш урман эшкәртү предприятиеләренә карата янгын куркынычсызлыгының мәҗбүри таләпләрен бозуларны кисәтүгә юнәлдерелгән күзәтчелек чаралары уздыруны тәэмин итәргә.

6.Муниципаль районның кабул итү эвакуация комиссиясе:

урман янгыннары утын торак пунктларга һәм гражданнарның җәйге ял объектларына күчкәндә халыкны эвакуацияләүне тәэмин итәргә, шул ук вакытта кирәкле санда техника, эвакуация урыннары, туклану һәм эвакуацияләнүчеләрне медицина белән тәэмин итүне алдан күздә тотарга кирәк.

7. Төрле милек формасындагы оешма җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

урман янгыннарын сүндерү планнары нигезендә урман янгыннарын сүндерү өчен көч һәм чаралар бүлеп бирүне тәэмин итәргә (оператив мобилизация планнары).

8.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе А. В. Хәбибуллин

Исп. И. М. Миңгалиев
Тел 8 (84367)31-112